**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БОЛГАР ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

КАРАР

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

№ 50

« 17 » декабрь 2025 ел

2025-2029 елларга шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуның яңа электрон хуҗалык кенәгәләрен салу һәм алып бару турында

«Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 07 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хуҗалык кенәгәләрен алып бару формасын һәм тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2022 елның 27 сентябрендәге 629 номерлы боерыгы нигезендә, һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу максатларында, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәр Башкарма комитеты

карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуның яңа хуҗалык кенәгәләрен 2025-2029 елларга авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең бухгалтерлык һәм махсуслаштырылган хисапларын җыюның һәм эшкәртүнең, җыелма хисаплар төзүнең, исәпкә алуны мониторинглауның, тикшереп торуның комплекслы мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон формада салуны оештырырга.һәм агросәнәгать комплексына ярдәм итүгә субсидияләрне анализлау.

2. Ел саен, 1 гыйнварга торыш буенча, шәхси ярдәмче хуҗалыкларны тоташ йөреп чыгу һәм шәхси ярдәмче хуҗалыклар әгъзаларын сораштыру юлы белән, 10 гыйнвардан 15 февральгә кадәр чорда шәхси ярдәмче хуҗалык башлыгы яисә китапларда күрсәтелгән шәхси ярдәмче хуҗалыкның башка әгъзалары тарафыннан белешмәләр җыюны гамәлгә ашырырга.

3. Хуҗалык кенәгәләрен алып барганда хуҗалык алып баручы гражданнар бирә торган мәгълүматның конфиденциальлеген, аның сакланышын һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә яклауны тәэмин итәргә кирәк.

4. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында //http:spasskiy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Болгар шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе: А.В.Костина

БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ